**Гражданнар Җыенының Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Косяково авылы торак пунктындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карары.**

**14 ноябрь 2024ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның «14» ноябрендә 8 сәгать 00 минутта, уздырылган гражданнар җыенының нәтиҗәсе белән «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлегенең Косяково авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I һәм II төркем инвалидлардан, хәрби бурычларын үтәгәндә имгәнгән хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, даими укучы студентлардан, җирлек территориясендә бер елдан артык яшәмәүче гражданнардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы сез?», дигән сорау буенча гражданнар Җыенының беркетмәсе төзелде:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (шул исәптән бу максатлар өчен инертив, төзелеш материаллары һәм кече архитектура рәвешләрен сатып алу, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру).

2) су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия булучылар исемлегенә 110 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 57, бу 52% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар Җыенының 57 катнашучысы тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлегенең Косяково авылындагы торак пунктта гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлегенең Косяково авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I һәм II төркем инвалидлардан, хәрби бурычларын үтәгәндә имгәнгән

хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, даими укучы студентлардан, җирлек территориясендә бер елдан артык яшәмәүче гражданнардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергэ дигэн карарны таныргa:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (шул исәптән бу максатлар өчен инертив, төзелеш материаллары һәм кече архитектура рәвешләрен сатып алу, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру).

2) су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

3. Әлеге карарны Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Аръягы»үзәге бинасы) шулай ук Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый информация рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы информация сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Норлат авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Норлат авыл җирлеге башлыгы — И.М.Саттаров